ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44, E-mail: archa@tatar.ru, www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

“ 26 ” июня 2024 ел № 441

**«2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча эшчәнлекне оештыру» максатчан программасын раслау турында» 2021 елның 08 декабрендәге 2217 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Җәмгыятьтән изоляцияләү белән бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгәннәрне һәм иректән мәхрүм итү, мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү буенча чараларны программага кертү максатыннан, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген оештыру» максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Программа чаралары. Максат. «2022-2026 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча эшчәнлекне оештыру» максатчан программасы нәтиҗәләрен бәяләү бурычлары, индикаторлары» дигән 6 бүлекнең «Хөкем ителгәннәрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру» дигән 3 бурычын 3.4 пунктча белән тулыландырырга һәм әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
26.06.2024 ел, №441
карарына кушымта

| 3 бурыч: «Хөкем ителгәннәрне ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру» | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.1 Төрмәдән азат ителгән, эчкечелек һәм наркоманлыктан интегүче затларны социаль реабилитацияләү эшенә дини конфессия вәкилләрен җәлеп итү | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районнындагы бүлеге, "Арча РУХ" ДАССО, ЭЭМның АМР буенча бүлеге (килешү буенча) | 2022-2026 еллар | Элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең гомуми күләме (процент) | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.2 Хөкем ителгәннәрне азат итү өчен Төзәтү учреждениеләрендә әзерлек мәктәпләре булдыру юлы белән хөкем ителгәннәрне киләчәк хезмәт эшчәнлегенә пенитенциар әзерләү буенча чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итү | АМР Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ДКУ, ТР хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районнындагы бүлеге, "Арча РҮХ" ДАССО, ЭЭМның АМР буенча бүлеге (килешү буенча) | 2022-2026 еллар | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.3 Төрмәдән азат ителгән балигъ булмаганнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын социаль реабилитацияләү эшенә иҗтимагый оешмалар вәкилләрен җәлеп итү | ТР хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районнындагы бүлеге, ЭЭМның АМР буенча бүлеге (килешү буенча), иҗтимагый оешмалар | 2022-2026 еллар | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.4 Җәмгыятьтән изоляцияләү белән бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән төзәтү учреждениеләреннән азат ителгән, ирегеннән мәхрүм итү, мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүче затларның социаль элемтәләрен торгызу, формалаштыру һәм ныгыту. Социаль һәм хокукый мәсьәләләр буенча консультацияләр бирү, юридик һәм психологик ярдәм күрсәтү, үз хокукларын тормышка ашыру өчен кирәкле документлар алуда ярдәм күрсәтү, эшкә урнашуда, белем алуда, пособиеләрдә, медицина ярдәмендә, пенсия, социаль хезмәтләр алуда ярдәм күрсәтү | АМР Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ДКУ, ТР хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча районнындагы бүлеге, "Арча РҮХ" ДАССО, Россия Социаль фонды (килешү буенча), УФСИН, ЭЭМның АМР буенча бүлеге (килешү буенча) | | | 100% | 100% | 100% | 100% | 100% | 100% | | | | | |